Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2019 ел №313

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль һәм муниципаль хезмәткәрләрне алмаштыручы затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакында» 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль вазифаларны биләүче затларның хезмәт хакын түләү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында социаль гарантияләрне тәэмин итү, тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, 2001 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе Хезмәт кодексы» 197-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы, 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән», 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль һәм муниципаль хезмәткәрләрне алмаштыручы затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакында» 83 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 6 октябрендәге 129 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 146 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 243 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

1.1.1. 4 бүлектәге «Квартал премиясе» 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Квартал премияләре муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазифаларны алмаштыручы затларга киметелә, район башлыгыннан тыш:

- билгеләнгән күләмнән 10%ка - муниципаль район башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, структур бүлек җитәкчесе йөкләмәләрен вакытында үтәмәгән һәм сыйфатсыз башкарган өчен, гамәлдәге законнар нигезендә алар тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән, доклад язуы нигезендә;

- билгеләнгән күләмнән 15%ка - муниципаль программаларны башкаручыларга һәм җаваплы затларга, региональ һәм федераль программаларны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп тормышка ашырмаган, яисә район бюджеты

акчаларын нәтиҗәле һәм максатчан куллануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән аерым чараларны үз вакытында тормышка ашырмаган өчен;

- билгеләнгән күләмнән 25%ка - муниципаль район башлыгы, район башкарма комитеты җитәкчесенең ашыгыч һәм аеруча мөһим беркетмә йөкләмәләрен сыйфатсыз башкарган өчен, гамәлдәге законнар нигезендә алар тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән;

- билгеләнгән күләмнән 15%ка - кисәтүләр рәвешендә бер дисциплинар җәза булган очракта;

- билгеләнгән күләмнән 25%ка – кисәтүләр рәвешендә ике дисциплинар җәза булганда;

- шелтә рәвешендә дисциплинар җәза бирелгәндә түләнми»;

1.2. 4 бүлектәге «Квартал премиясе» 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Эш бирүче дисциплинар җәза кулланганнан соң ел узганчы хезмәткәрнең үз инициативасы, үз үтенече һәм аның турыдан-туры җитәкчесе яисә хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы үтенече буенча төшереп калдырырга хокуклы.»;

1.3. 4 бүлектәге «Квартал премиясе» 4.8 пунктында «булырга мөмкин» сүзләрен төшереп калдырырга, «киметелгән» сүзләрен «киметелә» дип алмаштырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин